КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 6 апрель г.Казань № 236

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Индивидуаль эшмәкәр буларак дәүләт теркәвенә алганда, оештырыла торган юридик затны дәүләт теркәвенә алганда, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алганда, физик затны һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәпкә куйганда бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме күрсәтү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 29 май, 431 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Индивидуаль эшмәкәр буларак дәүләт теркәвенә алганда, оештырыла торган юридик затны дәүләт теркәвенә алганда, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алганда, физик затны һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәпкә куйганда бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме күрсәтү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 29 май, 431 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 4 май, 311 нче; 2017 ел, 6 декабрь, 938 нче; 2019 ел, 21 сентябрь, 863 нче; 2020 ел, 3 август, 645 нче; 2021 ел, 20 сентябрь, 885 нче, 2022 ел, 29 март, 287 нче, 2022 ел, 13 август, 817 нче, 2023 ел, 10 февраль, 124 нче, 2023 ел, 18 март, 278 нче, 2023 ел, 06 ноябрь, 1424 нче, 2024 ел, 30 гыйнвар, 44 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктның беренче абзацында «2023» саннарын «2024» саннарына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Индивидуаль эшмәкәр буларак дәүләт теркәвенә алганда, оештырыла торган юридик затны дәүләт теркәвенә алганда, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алганда, физик затны һөнәри керемгә салым

түләүче буларак исәпкә куйганда бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме күрсәтү тәртибенең 2.5 пунктында:

уникенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Эшкуарлык эшчәнлеген оештыруга эшсез гражданнарга бер мәртәбә финанс ярдәме күрсәтүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:»;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«гаризаны бирү көненә билгеләнгән тәртиптә агымдагы финанс елына эш белән тәэмин итү үзәгенә 1.2.1 Тәртипнең 1 пунктында каралган максатка җиткерелгән эшкуарлык эшчәнлеген оештыруга бер мәртәбә финанс ярдәме күрсәтүгә бюджет йөкләмәләре лимитларының булмавы (бетүе) һәм (яисә) гариза агымдагы елның 1 декабреннән соң килү;

гариза биргән датага кадәрге 12 ай дәвамында «Дәүләт социаль ярдәме турында» 1999 елның 17 июлендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон белән каралган индивидуаль эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга,шәхси ярдәмче хуҗалык алып баруга социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме алу.

Эш белән тәэмин итү үзәге әлеге пунктның ундүртенче абзацында күрсәтелгән эшкуарлык эшчәнлеген оештыруга, шул исәптән элек Россия Федерациясенең башка субъектында төзелгән индивидуаль эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга бер мәртәбә финанс ярдәме күрсәтүдән, шәхси ярдәмче хуҗалык алып баруга социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең булуын «Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа»дәүләт мәгълүмат системасы аша һәм (яисә) ведомствоара электрон багланышларның бердәм системасы аша тикшерә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин